ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.08.2024 ел Баулы шәһәре №106

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 августындагы 172 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 августындагы 172 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «ТР КоАП статьялары» графасында 3.2 статья исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2 статья. ТР Административ хокук бозулар кодексының Урамда сәүдә итүне оештыру һәм халыкның күңел ачуына бәйле хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозу»;

- «3.15 статья. «ТР Административ хокук бозулар кодексының җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә»:

| | |
|---|---|
| «3.15[1]. статья Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәтләрне күчләп тагу | - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм балигъ булмаганнарның хокукларын яклау бүлегенең әйдәүче белгечләре;». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Д.Л. Бакиров